ҮЗЕБЕЗЧӘ ОЛИМПИАДА
Спорттан өметнең дә, кызыксынуның да өзелгәне юк
> 2

ҮЗАРА САЛЫМ
Авыл кешесе аның авыл өчен кирәк булуына ышанды инде
> 3



ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ
Беренче карашка гына шулай тоелды ул, ә икенче мизгелдә бөтенләй куркыныч булып китте
> 4

ЮЛЛАР УРТАК
«Милләт» белән «дин» төшенчәләрен бер яссылыкта карарга мөмкинме?
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 115 (28888) | Чәршәмбе | 10 август | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

СОҢГА КАЛСАҢ, ЭШ ПЕШМИ

Вузларда

«ПромРейтинг» агентлыгы республикадагы иң яхшы ун вузны ачыклаган. Билгеле булганча, бәйсез исемлек ел саен әти-әниләр һәм абитуриентлар фикереннән чыгып төзелә. Беренче баскычта – КФУ. Шулай ук Казан медицина университеты, Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты (КДАТУ), Казан илкүләм тикшеренүләр техник университеты (КАИ), Иннополис университеты – алдынгы урыннарда. Быел мәктәпне тәмамлаучылар кайсы вузларны сайлаган?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Рейтинг июнь – июль айларында, бердәм дәүләт имтиханнары чорында уздырылган сораштырулар нәтиҗәләрен исәпкә ала. Исемлек 21 юнәлештән тора. Алар арасында югары уку йортының ни дәрәҗәдә популяр булуы, белем сыйфаты һәм башка күрсәткечләр бар. Әйтик, «Кайсы вузга керү иң авыры?» дигән сорауга абитуриентларның 38,1 проценты КФУга дип җавап биргән. Икенче урында – Казан медицина университеты (31,8), өченчедә – Иннополис университеты (30,2). Шулай ук КЮИ, КАИ, КДАТУны атаганнар. Абитуриентлар фикеренчә, иң сыйфатлы белем КФУ, Иннополис, Казан дәүләт медицина университетларында бирелә. Ә иң сыйфатлы гуманитар белем бирүче вузлар – КФУ, Социаль һәм гуманитар белем бирү институты (ИСГЗ), Казан инновацион университет (КИУ). Иң яхшы техник белемне КАИ, КХТИ, КФУ, Казан дәүләт энергетика университеты, Иннополис университетында бирәләр дип саныйлар. Традицияләр сакланган вуз дип КФУ, Россия ислам институты (РИИ), Казан дәүләт аграр университет, КДМУ табылган. Үз студентларына КФУ, Иннополис, КИУ, ИСГЗ күбрәк ярдәм итә икән. Һәрхәлдә, студентлар шулай уйлый. Иң яхшы түләүле вузлар исемлегендә КИУ, ТИСБИ, Казан кооперация, Казан эшмәкәрлек һәм хокук институтлары урын алган. Ә кайсы вузга керүне яшьләр хупламаган? Андыйлар рәтенә Казан кооперация университеты, ИСГЗ, ТИСБИ, РИИ, Социаль белем бирү академиясе (КСЮИ) керткәннәр. Кызлар өчен алдынгы дип КФУ, КДМУ, Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе, КИУ, Иннополис, Казан мәдәният университеты табылган. Егетләр күп укый торганы – КДТАУ, КФУ, КАИ, Иннополис, Казан югары танк мәктәбе. Сораштыруда катнашучылар фикеренчә, Казан медицина университеты һәм Казан федераль университеты, Казан кооперация университеты дипломнары дөнья күләмендә күбрәк бәяләнә.

Рейтинг нәтиҗәләре күрсәткәнчә, әти-әниләрнең күбесе балаларын IT-белгеч, инженер, икътисадчы, табиб итеп күрергә тели. Ә менә бүгенге заманда хисапчы, эколог, риелтор, очучы, психологны өметле дип санамыйлар. Чыгарылыш сыйныф укучылары исә IT-белгеч, психолог, хәрби, хокук белгечлеге алуны хуплый. Тик, алар фикеренчә, бүген слесарь-механик, бухгалтер, очучы, машинист-йөртүче булу популяр түгел. Әти-әниләр күбрәк тотрыклы эш урыны яклы булса, балалар киләчәктә язмышларын коммерцияле оешмалар белән бәйләүне хуплый.

Ниһаять, вузларда бюджет бүлегенә укырга керүчеләрнең исемлеге билгеле булды. Быелгы абитуриентлар киләчәктә кем булырга җыена?

Ахыры 2 нче биттә >

Сентябрьдә төгәллиләр

Урман хуҗалыгы министрлыгы матбугат хезмәте хәбәренә караганда, быел Татарстанда 2,8 мең гектар мәйданда урманнар яңартылган. Шул исәптән 1,4 мең гектар мәйданда киселгән, карт агачлар яшьләренә алыштырылган, 104 гектар буш мәйданда үсентеләр утыртылган. Тагын 4 гектарында урманнарны катнаш яңарту эшләре башкарылган (карт агачлар да алыштырылган, бушлыкларда да агачлар пәйда булган). Шул ук вакытта 1,3 мең гектар мәйданда элегрәк утыртылган яшь үсентеләрне карау-тәрбияләү эшләре хәл ителгән. Төбәк урманчыларына тагын 754 гектар мәйданда тиешле чаралар башкарырга кирәк. Барлык эшләр сентябрь башында төгәлләнергә тиеш. Моннан тыш урман хуҗалыклары белгечләре агач орлыкларын әзерләү эше белән дә мәшгуль. Хәзерге вакытта алар каен орлыкларын җыя.

Бу эшләр «Экология» илкүләм проектының «Татарстанда урманнарны саклау» төбәк проекты буенча башкарыла.

Берсе килә, берсе китә

Татарстанда бу елның биш аенда: гыйнвар – май чорында безгә эшләргә (укырга) килүчеләр саны арткан. Узган елның шушы ук чорындагы белән чагыштырганда республикага 2381гә күбрәк мигрант (үсеш – 4%) килгән. «Реальное время» язганча, Татарстан Идел буе федераль округында бердәнбер шундый төбәккә әйләнгән.

Татарстанстат мәгълүматларына караганда, биш айда барлыгы 34 меңнән артык кеше кабул ителгән. Шушы вакыт эчендә 31652се киткән. 20191 очрак республика эчендәге миграциягә карый.

Тышкы миграциягә килсәк, гыйнвар – май айларында республика 13842 кешене кабул иткән. Шуның 8661е – башка төбәкләрдән, 4751е – БДБ илләреннән, 430ы – башка чит илләрдән.

Укыган кеше хур булмый

Татарстанда 8 мең эшсез дәүләт хисабына яңа һөнәргә өйрәтеләчәк. Шуның 60 проценты яңа белемнәр үзләштерүгә керешкән дә инде. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова «Татар-информ» хәбәрчесенә сөйләп үткәнчә, иң элек 3 яшькә кадәрге бала карау ялындагы яшь аналар, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге сабыйлар үстерүче эшсез ханымнар бу. Урта яки югары һөнәри белемгә ия булмаган 35 яшькә кадәрге яшьләргә дә шундый ук ярдәм күрсәтелә. Диплом алып, 4 ай эчендә эшкә урнаша алмаучылар да яңа һөнәр үзләштерү мөмкинлегенә ия. Быел югары яки махсус урта уку йортын тәмамлап, эш таба алмыйча, Мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән егет-кызлар үзләренә кулай һөнәргә өйрәтеләчәк дигән сүз.

Тагын бер зур юнәлеш – сәнәгать предприятиеләренең эштән китү куркынычы янаган хезмәткәрләренә ярдәм кулы сузу. Алар йөртүче, монтажчы, ягулык станцияләре операторы, электр-газ белән эретеп ябыштыручы, тракторчы, тегүче, хисапчы, мәгълүматларны компьютерда эшкәртүче кебек бик кирәкле һөнәрләргә өйрәтеләчәк.

Төзеп тә карыйлар

Татарстанда быелга торак төзү планы 79 процентка үтәлгән инде. Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин әйтүенчә, планда 2,8 миллион квадрат метр торак мәйданы төзү каралган. Бүгенгә шуның 2 миллионнан артыграгы инде әзер дә икән. Аның әйтүенчә, ел азагына кадәр әлеге бурычны үтәү генә түгел, узган елгы рекордка ирешү ихтималы да бар. Министр искә төшереп үткәнчә, 2021 елда Татарстан, 3,1 миллион квадрат метр торак мәйданын файдалануга тапшырып, рекорд куйган.

Сүз уңаеннан, быел планның 40 проценты чамасы – күпфатирлы йортлар, 60 проценты шәхси торак төзелешенә туры килә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

COVID-19

Саклангарны саклар

Коронавирус үзенең кара саннары белән кабат куркыта башлады. Россиядә узган тәүлектә әлеге инфекцияне йоктыручылар саны 16325кә җитте. Үлүчеләр – 60 кеше. Моңа кадәр чирдән үлүчеләр саны 45 иде.

Сырхауны җиңүчеләр саны да арткан, диләр оператив штаб вәкилләре. Узган тәүлектә 13092 кеше дәваланып чыккан. Моңа кадәр 8721 кеше иде.

Дөнья күләмендәге саннар тагын да ныграк сагайта. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы хәбәр иткәнчә, коронавирус йоктырып авыручылар саны 580 млн кешедән артып киткән. Аннан үлүчеләр саны – 6,41 млн. Авыручыларның кисәк артуын 5 августтан башлап теркиләр. Чагыштыру өчен: 14 апрельдә – 500 млн, 10 февральдә – 400 млн, 8 гыйнварда – 300 млн, узган елның августында – 200 млн кеше.

Вазгыятьнең кискенләшә баруын кешеләр үзләре дә чамалый булса кирәк. «Чек Индекс» хезмәте белгечләре ачыклавынча, июль аенда шәхси саклану чараларын (СИЗ) сатып алучылар саны кисәк кенә арткан. Әйтик, битлекләрне – 17 процентка, антисептикларны 4 процентка күбрәк сатып ала башлаганнар. Кулланучыларның күбесе – пандемия чорында саклану чараларына ияләшкән, алардан даими файдаланып торган кешеләр икән.

Битлек кию, антисептик куллану – бер нәрсә. Иммунитетны көчәйтү турында да онытмаска кирәк. Моны белгечләр дә кат-кат искәртә.

Россия Фәннәр академиясе академигы, атказанган табиб Геннадий Онищенко сүзләренчә, уку елының башлануы һәм көннәрнең суытып җибәрүе коронавируслы вазгыятькә тискәре тәэсир итәргә мөмкин. Шуңа күрә вакцина ясатуны озакка сузмаска кирәк. Табиб сүзләренчә, бу чорда салкын тиеп авырулар да арта, симптомнарсыз гына уза торган «омикрон» да куркыныч.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстандагы вазгыятькә килгәндә, бер тәүлектә COVID-19 чирен йоктыручылар саны 71 кеше булган. Үлем-китем очраклары теркәлмәгән. 56 кешене сырхауханәгә озатканнар.

2022 елның 1 июленнән коронавируслы сырхаулар белән эшләүче медицина хезмәткәрләре өчен түләүләрне исәпләү кагыйдәсе үзгәрде. Хөкүмәт карары нигезендә шәфкать ияләре окладка 25 процент өстәмә акча алачак. COVID-19 инфекциясен йоктырган сырхауларга ярдәм күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә башка матди өстәмәләр исә Россия Президенты Указы белән гамәлдән чыгарылды.

Сүзгә-сүз

Виктор САДОВНИЧИЙ, Мәскәү дәүләт университеты ректоры:

Болонья процессы безгә кирәкми. Милли белем бирү системасына күчү илебез мәгарифен үстерүдә яңа адым булачак. Россия халкының үз менталитеты бар. Без тәрбия һәм белем бирүдә Көнбатыштан кертелгән алымнарны күчерергә тиеш түгел. Бакалавриат белем бирү дәрәҗәсен күтәрергә булышмый. Безнең вуз әлеге системага күчмәде, студентларны специалитет һәм магистратурада укытабыз.

(«Парламентская газета»дан)

ИҢ ХӨРМӘТЛЕ ҺӨНӘРЛӘР

«Работа.ру» хезмәте белгечләре Россия халкыннан: «Кайсы һөнәр ияләренә хөрмәт белән карыйсыз?» – дип сорашкан. Сораштыруда катнашучылар иң аз тавышны төзүче, эколог, шахтер һәм IT белгечләргә биргән.



51% >> укытучылар

50% >> табиблар

36% >> янгын сүндерүчеләр һәм коткаручылар



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ТАЙБӘЙНЫ НИК КОМСЫЗ КАЛДЫРАЛАР?

Глобаль икътисад кризисы фронтларыннан торган саен өметсезрәк хәбәрләр килә. «Европа икътисади түнтәрелешкә әзерләнә, – диде соңгы көннәрдә генә Финляндия Президенты Саули Ниинисте. – Һәм хәл елдан-ел уңайлануга таба бармас». Көнбатыштагы хәлнең начараюына «ура-патриот»лар сөенәләр сөенүен, әмма хәзерге икътисад домино эффектына корылган. Бер домино ауса, бөтен конструкция җимерелә. Европа түнә икән, Кытай да ава, Кытай ауса, Россиядә дә рәхәт булмый. Кытай исә бер дә шатлыклы хәбәрләр таратмый. Пекин глобаль кризисның флагманы булырга, аның маховигы ролен үтәргә җыена. Хәзерге икътисади түнтәрелеш моңарчы без күргән-ишеткән рецессияләрдән зур хәрби конфликт төенләве белән аерыла. Гадәти базар рычаглары белән кризистан чыгып булмый инде. Державалар шуңа күрә конфронтация сукмагына чыга. Сугыш әрдәмендә алар: а) массаларның игътибарын читкә юнәлтергә; ә) базарларны яңадан бүлешергә; б) яңа дөнья тәртибе дип, үз ихтыярларын башкаларга көчләп тагарга җыена. Хәвеф бик зур булуга карамастан, һәр башкала сугыштан, җиңүче булып имин чыгармын, дип өметләнә.

Хәлне тәзәтеп булмый икән, аны тагын да начарайтырга кирәк. Көндәшләр ныграк сызлансын өчен, икътисади элемтәләрне өзәргә, базарларда кытлык тудырырга, килеп туган хәлдә дошманнарны гаепләргә... Без боларны «пандемия кризисы» дип аталган 2020 елда башланган шаукымда гаҗәпләнеп бер күзәттек инде. Коронавируска карышы көрәш чаралары үзләренең мантыйксызлыгы белән барыбызны да таң калдырды. Кытайда исә алар аеруча ерткычларча оештырылды һәм оештырыла. Әмма барлык кыенлыкларны да пандемиягә сылтап бетерү мөмкин түгел. Игътибарны тышкы дошманнарга юнәлтергә туры килә. Тайвань мәсьәләсен кискенләштерү агымдагы вазгыятьтә шуның өчен кирәк тә инде. Тайваньның төп сәүдә партнерлары, мәсәлән, кемнәр? АКШ Тайбәйдән 105 миллиард долларга товар ала, Япония – 85, Германия – 20 миллиард долларга. Алар барысы да нигездә утраудан алыштыргысыз микрочиплар алалар. Дөнья базарының 53 процентын тотып торучы TSMS компаниясе, мәсәлән, 5 нанометрлы микросхемалар җыя. Чагыштырыгыз: Россиядә 90 нанометрлы микросхемалар гына җыя алалар. Хәзерге җиһазларда 14 нанометрлылар кулланыла. Тайвань чипларны кебек нечкәне АКШта да әлегә җыя алмыйлар. Тайвань тирәсендә өйрәнүләр оештырып, Кытай аның төп партнерларына кисәтү ясый. Әмма хәрби блокаданы озак тотып булмый бит. Пекин Тайваньга ком сатуны туктатты. Кытай комыннан башка ярымүткәргечләр ясап булмый. Тайваньнан ярымүткәргечләр килү туктаса, зур державаларның җитештерүе тормозга басачак.

Кытай тагын бер зонада – Бохай бугазында хәрби өйрәнүләр башлап җибәрде. Алар 8 сентябрьгә кадәр барачак. Бохай Тайваньнан ерак, әмма Пекинга якын. Сентябрьдә компартия съезды ачылачак. Шул датага якын китереп, илдә тәсле революция оештырырга теләгән көчләр бар, диләр. Армиянең кул астында булуы Пекинга бу юлы шуның өчен кирәк.

Кытайдан килгән соңгы яңалык та сөенердәй торган түгел. Анда «ланье» дип аталган яңа куркыныч вирус табылды. «Ковид-19»га караганда күбрәк үтерә торганы. Авыруның кешедән кешегә күчәме икәне әлегә мәгълүм түгел. Дәвасы юк. Эшләр шулай барса, Кытай безне кая кадәр илтеп җиткерер, шулай ук белмибез.

Россиядә

ТАМАК КЫСЫП, АЛГА КИТЕП БУЛАМЫ?

Дөньякүләм хәлләрнең начараюы Россиядә дә үзен сиздерми кала алмый. Тиңсез санкцияләр бокрасында калу шартларында хәлебез тагын да авыррак була алыр иде әле, әмма тышкы базарларда углеводородлар кытлыгы безне әлегә тамам төпкә китүдән саклый. Көнбатышлылар безнең газга бәйләлектән котылу өчен нинди генә юллар эзләмиләр. Италиянең Maire Tecnimont компаниясе чүплекләрдән углерод һәм водород «сыгып алырга» җыена. Килачәктә шул юл белән табигый газның ун процентын алыштырырга телиләр.

Россия җитештерүчеләре исә чит илгә бәйлелектән тиз генә котылып булмасын төшенделәр инде. Бер вице-премьерның «Импортны алыштыру чит ил компонентлары булмау сәбәпле тукталды» дигән сүзләре, каналтыга әйләнеп, «Телеграм» каналында «очып йөри». Металлурглар, әйтик, чит ил җиһазларыннан котылырсыз бәйлелектә яши. Прокат станнарына тукталу куркыныча яный. Тармакны 2030 елга кадәр үстерү стратегиясендә чит ил комплектлаучы детальләрен алыштыру өчен ун елдан артык вакыт кирәк булачагы әйтелә.

Югары икътисад мәктәбе белгечләре Россиянең 25 төбәгендә генә икътисади активлык үсешен күрәләр. Ел башында 72 төбәк активлык күрсәткән.

Илнең технологик яктан артталыгының объектив сәбәпләре бар, билгеле. Хай-тек (яңа технологияләр) өчен акча бик кысып кына бирелгән. Технологияләр тармагы чиновникларга түләүгә караганда 30 тапкыр азрак финансланган. Алгарышлы фән өчен без акчаны АКШка караганда 442 тапкыр кимрәк тотканбыз. 2021 елда технологик компанияләр өчен АКШта – 353,8, Кытайда – 91,3, Бөекбританиядә – 54,9, Һиндстанда – 41,7, Австралиядә – 25,5, Россиядә 0,8 миллиард доллар акча тотылган. Ярдәм сорап, хәзер Һиндстанга барып егылуыбыз гаҗәп түгел инде, калган лидерларның күбесе «дус булмаган» илләр исемлегендә бит.

Россиянең икътисади күрсәткечләре карап торышка бик яхшы күренә күренүен. 2021 елның гыйнвар – июнь айларында тышкы сәүдә профициты 70 миллиард доллар булса, быелның шул ук чорында 158,4 миллиард долларга җиткән, ягъни күп экспортлаганбыз, аз импортлаганбыз. Әмма мондый профицит безнең тамак хәлен бер дә яхшыртмый икән. Россиялеләрнең азык-төлек сатып алу мөмкинлеге рекордлы рәвештә түбәнәйгән. 2022 ел соңгы ун ел эчендә иң ач елга әверелгән. Кешеләр ТКХ өчен түләүне дә күбрәк кичектерә башлаганнар. Быелның беренче кварталында үткән елның шул чоры белән чагыштырганда ТКХ бурычлары 7,6 процентка артып, 804,5 миллиард сумга җиткән.

ТАШ АТКАНГА... ЯРЫШ БЕЛӘН ҖАВАП

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫ СПОРТ ЯРЫШЛАРЫ ҮТКӘРҮДӘН ТУКТАМЫЙ

Спорттан өметнең тә, кызыксынуның да өзелгәне юк. Зур ярышлар уздыруга, катнашуга киртә куелса да, үзебездә ярышлар тыелмаган. Җиңәм дип торган спортчылары булганда, бигрәк тә. Татарстанның спорт министры Владимир Леонов соңгы арада узган ярышларга нәтиҗә ясады. «Киләчәктә ниндиләрен көтәргә?» дигән сорауга да җавап бирде.

tatarstan.ru

«Дуслык Уеннары» кызыксындырган

Сәяси шаукым спорт дөньясына да тәэсир итми калмады, билгеле. Мәгълүм сәбәпләр аркасында, халыкара спорт оешмалары Россиядә ярыш-уеннар уздырудан бер-бер артлы баш тартты. Йөзү буенча ике дөнья чемпионатын кабул итәсе башкала идек югыйсә. Әмма «булмый инде булмагач» дип кенә утырмадылар. Татарстанда яңа ярышка старт бирелде. Министр әйтүенчә, уңышлы гына узды ул.

– 22 июль – 3 август аралыгында Казанда «Дуслык Уеннары»ның беренче этабы оештырылды. «Дөнья» дип аталган этапта йөзүчеләр, синхрон йөзүчеләр, суга сикерү буенча осталар көч сынашты. Тагын ике этап ноябрь һәм декабрь айларына билгеләнгән, – диде Владимир Леонов. – Беренче этапта катнашуга 28 ил гариза тапшырган иде. 16сы гына килде. Минемчә, киләсе этапларда илләр саны күбрәк булачак. Спортчыларның Казанга килергә теләкләре зур. Беренче этапта Россия, Алжир, Әрмәнстан, Белоруссия, Венесуэла, Вьетнам, Сербия, Казахстан, Сүрия, Судан, Таҗикстан, Үзбәкстан, Эквадор, ЮАР, Донецк һәм Луганск халык республикаларыннан спортчылар катнашты. География шактый киң. Катнашучылар саны да аз түгел.

Ярышларның саллылыгы катнашучылар саны белән генә түгел, тамашачылар күрсәткече белән дә үлчәнә бит әле. «Дуслык Уеннары»н тәнкыйть утына тотучылар да булмады түгел. Яңәсе, трибунада халык аз. Министр исә киресен дәлилләде.

– Тамашачылар ярышларга бик теләп йөрде. Дөресен әйткәндә, мондый зур кызыксыну безне дә гаҗәпләндерде. Әле яңа ярыш бит. «Дуслык Уеннары»на узган елгы халыкара ярышларга караганда да күбрәк кеше килде. Көз, кыш узачак этапларда да кызыксыну тагын да артыр дип ышанам, – диде Владимир Леонов.

Сүзләрен саннары да куәтли. 14 көнлек ярышларны 13,6 мең тамашачы караган. Йөзү белән аеруча кызыксынганнар. Анысына 8717 кеше килгән. 1340 кеше суга сикерү, 3549 кеше синхрон йөзү ярышларын караган.

Моннан тыш уеннарны «Матч ТВ» каналы аша да карарга мөмкин иде. Министр китергән мәгълүматка ышансаң, башкаладагы ярышларны 12,5 млн тамашачы күргән. Иң зур кызыксыну синхрон йөзүгә булгандыр, дип фаразлый Владимир Леонов.

«Дуслык Уеннары»нда 376 комплект медаль (1128 медаль) уйнатылган. Россия исеменнән чыгыш ясаган спортчыларның уңышлары исә мондыйрак: йөзү буенча – 224, суга сикерүдә – 42, синхрон йөзүдә 27 медаль яулаганнар.

«Дуслык Уеннары»н даими ясарга кирәк дигән теләк-нияткә тә бар. Беренче этап булган барлык мөмкинлекләрдән файдаланып, министр сүзләре белән әйткәндә, аяк өстендә яңа турнир булса, ноябрь – декабрьгә билгеләнгәннәрен күбрәк иганәчеләр җәлеп итеп үткәрергә булыр иде. Аннан инде ел саен оештыра торган итеп тә булмасмы.

Үзебезчә Олимпиада

Бүгеннән исә Җәйге спорт төрләре буенча Россия субъектлары арасында I илкүләм Спартакиада башлана. Анда 39 спорт төре буенча 13 меңгә якын кеше көч сынашачак. Спартакиада 2 октябрьдә тәгәлләнәчәк.

– Халыкара ярышларда Россия катнаша алмый. Бу чара да менә шуңа күрә үткәрелә инде. Саннарга карасак, Спартакиада Җәйге Олимпия уеннарыннан ким булмас төсле. Ул Россиянең бер генә шәһәрендә узмаячак. Казаннан тыш ярышларны Мәскәү, Мәскәү өлкәсе, Санкт-Петербург, Краснодар, Чиләбе, Тула һәм башка өлкәләр кабул итә. Без исә ярышлар саны буенча икенче шәһәр булып торабыз, – дип аңлатты Владимир Леонов.

Татарстан башкаласы 11 дисциплина буенча ярышлар кабул итә. Спортчылар Казанда суга сикерү, волейбол, ату, чирәмдәге хоккей, дзюдо, көрәш, бию, гимнастика, самбо һәм ишкәкле спорт буенча көч сынашачак. Татарстан да үз командасын тәкъдим итә.

– Турнирда 400 кешедән торган Татарстан командасы да катнаша. Алар 33 спорт төре буенча ярышачак. «Иң-иң»нәрне сайлап алдык. Аларның күрсәткечлек осталыклары бар, – диде Владимир Леонов.

Өметле балалар

Шушы көннәрдә Владивостокта «Азия балалары» халыкара уеннары тәгәлләнде. Татарстан командасы да буш кул белән кайтмады аннан. Министр, журналистлар белән очрашкач, өметле яшьләрне дә телгә алды.

– Республиканың җыелма командасы составында 47 спортчы 11 төрле ярышта көч сынашты. Нәтиҗәләргә килгәндә, балалар 35 медаль яулап кайтты. Шуларның 15е – алтын, 7се – көмеш, 13е – бронза медальләр. Гомум команда зачетында алар 5 нче урынны яулады, – диде Владимир Леонов. – Безнең команда турнирда иң күп кешеле булмаса да, лаеклы чыгыш ясады. Спортчыларыбыз, башка зур командаларны да узып, Казанга күп бүләк алып кайта алды.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

СОҢГА КАЛСАҢ, ЭШ ПЕШМИ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Мин документларны биш вузга бирдем. Шуларның дүртесен – Санкт-Петербургка, берсен – Казан мәдәният институтына. Ни өчендер мине Казан федераль университеты бер дә кызыксындырмады. Беренчедән, анда күбрәк читтән килүчеләрне алалар. Икенчедән, дизайн юнәлешен алай ук көчле дип санамыйлар. Мине беренче чиратта сыйфат кызыксындыра. Ниндидер могҗизалар эзләү өчен читкә китмим, – ди Казан кызы Мәрьям Мортазина.

Мәрьямне күбрәк иҗади юнәлешләр кызыксындырган. Дизайн, рәсем ясау, архитектура, журналистика, фото сәнгате... Шул ук вакытта мәктәптә математиканы да яхшы укыган ул. Бу фәннән репетитор да булган әле. Мәрьям фикеренчә, абитуриентларны тегендә-монда сикереп йөриләр, һөнәргә тугры түгел, дип сүгәргә кирәкми. Бер генә урынга документлар тапшырсаң, авыз ачып калуың да бар. Ул үзе биш вуздагы исемлекләр әйләнешен көннәр буе күзәткән. Менә монысы бер дә рәхәт түгел, ди.

– Укырга теләгән кеше укый инде ул. Әнә бер сыйныфташым БДИдан шактый яхшы баллар җыйса да, аның вузда уку теләге юк. Көллияткә керәм, ди. Шуңа күрә һәркем үз юлын үзе теләгән җирдә таба, – ди ул.

Вузлардагы вазгыятьне дә белештек. КНИТУ-КАИның кабул итү кампаниясе киңәшчесе Светлана Шәвәлиева әйтүенчә, быел яшьләрне, гадәттәгечә, программист, инженерлык юнәлешләре кызыксындырган, кайбер әзерлек юнәлешләренә бик зур бәйгеләр булган.

– Безгә төрле студентлар килә: югары баллылар да, түбәнрәкләр дә. Түбәнрәкләр 190–200 баллылар санала. Тәҗрибәм буенча, бу баллар белем түбән икәнен күрсәтми, андыйлар, киресенчә, кайвакыт яхшырак, тырышырак та укый башлый әле. Гомумән, бик акыллы, укырга теләүче абитуриентлар байтак. Документларны бернәчә вузга бирү мөмкинлеген начар дип санамыйм, – ди галимә.

Светлана Шәвәлиева белдергәнчә, быел документларның оригиналын (төп нөсхәсен) китерү буенча матавыклар килеп чыккан. Аны 3 августка кичке сәгать 6га кадәр тапшырырга кирәк иде. Монда өч юсудан файдаланырга мөмкин. Беренчесе – университетка килеп тапшыру. Икенчесе – университет сайты аша гариза язып, документларның фотоларын беркетеп, аттестат оригиналын почта аша җибәрү (ерак җирләрдә яшәүчеләр өчен инде бу, мәсәлән, быел Ханты-Манси округыннан берәү шулай юллады). Өченчесе – Дәүләт хезмәтләре порталы аша җибәрү. Быел бу мөмкинлек беренче тапкыр тудырылды. Порталда биш вуз сайлап, гариза язып, документларның фотоларын беркетеп, «Ризалыкны белдерергә» дигән төймәгә генә басарга кирәк иде. Бу исулларның өчесе дә – үз урыныңда, кенәгә ничек уңайлы бит.

– Тик конкурстан үтү мөмкинлеген фаразлау кыенлык тудырды, чөнки мәгълүмат минут саен үзгәреп торды, системага килгән гаризаларны эшкәртеп бетерергә вакыт кирәк бит. Шуңа күрә сәгать 6 тулганда конкурстан үткән кайбер балалар инде бер сәгатьтән соң керми калганнарын белде. Бик кызганыч, әлбәттә. Дәүләт хезмәтләре порталы аша ризалык җибәрү бер көн алдан булса да тукталса, андый кимчелекләр азрак булыр иде, дип уйлыйм, – ди белгеч.

САК БУЛЫГЫЗ: ЧУМА

Моңа кадәр хайваннар арасында йогышлы авырулар таралу буенча имин булып саналган Татарстанда күңелсез хәл килеп чыкты. Спас районының Идел буе бистәсендә шәхси хуҗалыктагы дуңгызларда Африка чумасы табылган.

newsbryansk.ru

Е. Федоров хуҗалыгында барлыгы дүрт дуңгыз булган, аларның икесе үлгән. Харап булган терлекләрне тикшергәч, хайваннарда Африка чумасы булуы расланган. Шуннан соң ветеринарлар терлекләрнең барысын да юкка чыгарган, территориягә дезинфекция үткәргән. Вирус табылган зонада профилактик эшләр алып барыла. Шунысы куанычлы: авыру килеп чыккан территориядә дуңгызчылык комплекслары юк.

Вирусның каян килеп чыгуы әлегә тәгәл билгеле түгел. Шулай да авыру кыргый хайваннардан күчкән яки ризык белән кергән булырга мөмкин, дип фаразлыйлар.

Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе безгә хәбәр итүенчә, әлеге вакытта куркыныч авыруны булдырмый калу максатыннан ветеринар-санитар чаралар оештырыла, оештыручы хуҗалык эшләре алып барыла.

– Дуңгызларда Африка чумасы белән вазгыять катлаулы. Шуңа күрә барлык саклык чараларын күрегез, – дип кисәтә белгечләр. – Хуҗалыкларында дуңгыз тотучылларга, дуңгызчылык белән шөгыльләнүче оешма җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләргә бик җаваплы һәм игътибарлы булырга туры киләчәк. Хуҗалык территориясенә вирусны алып кермәс өчен, оешмаларга ябык режимда эшләргә, урманнарга бармаска һәм барлык ветеринар таләпләрне үтәргә кирәк.

Билгеле булганча, әлеге авыру – бик җитди. Чума белән авырый башлаган дуңгыз исән калмый. Калсалар да, алар үлгәнче вирус йөктыручы булып санала. Хайван авыруны туфрак, су, ризык аша йөктыра. Кеше һәм башка терлекләр авырмаса да, авыру бик зур икътисади зыян китерә.

– Урманга гөмбәгә, җиләккә йөрүчеләр – авыру таратуның бер юлы. Без аларны тыя алмыйбыз, әлбәттә, әмма саклану чаралары турында һәркем уйларга тиеш. Вирус кабан дуңгызлары йөргән җирдән аяк киеменә ияреп кайтырга мөмкин. Барган очракта да, кайткач, ишегалдына, дуңгызлар янына барайта кергәнче, аяк киемнәрен дезинфекцияләргә кушабыз, – ди белгечләр.

Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе урынбасары Габделхак Мотыйгуллин сүзләренә караганда, әлеге авыру Россиядә беренче тапкыр 2008 елда теркәлгән. Аннан довалау чарасы юк. 95–100 процент очракта ул үлем белән тәмамлана. Гадәттә, бу вирусны йөктырган дуңгыз 3–5 көн эчендә үлә. Африка чумасы эләктергән дуңгызда клиник билгеләр 2–22 тәүлек арасында сизелә башларга мөмкин. Чирнең беренче билгеләре – дуңгызның тән температурасы 41–42 градуска кадәр күтәрелү. Моннан тыш, авыру дуңгызның сулышы ешая, тәне тимгел-тимгел кызара, кызыл сипкелләр күренә. Тәненең төрле урыннарында шәмәхә төстәге таплар пәйда була. Авырып терелгән очракта да, мондый дуңгыздан котылу ягын карарга кирәк, чөнки ул барыбер вирус йөртүче булачак. Авыру шулай ук кыргый хайваннар, терлек ризыгы, кошлар, кимерүчеләр һәм бөҗәкләр аша да таралырга мөмкин. Шуңа күрә белгечләр халыкка дуңгызларны сарайдан чыгармый йөртмәскә киңәш итәләр.

Моннан тыш, малларны сатып алганда да зур саклык чаралары күрергә кирәк. Махсус сату урыннарында ветеринардан алынган озата баручы документлар булырга тиеш, ди алар.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Шәҗәрә

Авыл тарихын барлаганда, туган җиргә ныграк бергәсең кебек. Шулай булмый хәл дә юк: күпме авылдашларыңның язмышы күз алдына килеп баса бит. Үткәннәрне бүгенге белән бер челтәргә үрергә тырышасың. Нәсел җепләре өзелмәсен иде, дип хыялланасың. Кемне генә тыңласаң да, бер гаиләнең бөтен илдә, дөньяда булган вакыйгаларны үз эченә алганлыгына гаҗәпләнәсең.

БАБАЙЛАР КАЛДЫРГАН ЭЗ

Бервакыт шулай төш күреп ятам. Күз алдымда күршедәге Хәйрикамал апа белән Нурулла абыйлар арасында бер йорт пәйда була. Элегрәк замандагы кебек. Кешеләре дә бар. Ишегалдында тыз-быз йөрешәләр, әмма таныш йөзләр юк. Бу хакта шул йортларга каршы якта яшәгән Рәфхәт абый Фазлыевка сөйләгән идем. Шаккатты. Баксаң, бу ике йорт арасында аның әнисе Рәмзия апа туып-үскән нигез икән. Әнисе, шул урында йорт салып, берәр улын башка чыгарырбыз дип хыялланган да булган. Әмма заманында колхоз рәисе булып эшләгән Нурулла абый яңа йортын алар биләмәсенә кертеп салган. «Әнием моңа бик борчылып йөрде. Әмма «халык дошманы» кызы булгач, каршы сүз әйтә алмагандыр, күрәсең. Ә Нурулла абый үләр алдыннан, урынга яткач, әнине чакырып, бәхиллеген сорады», – дип искә алды Рәфхәт абый.

Бүген Фазлыевлар нигезендә Рәфхәт абыйның энесе Фирдәвес яши. Бай тарихлы нәсел бу. Шәҗәрә дә төзегәннәр. Кайчандыр әти-әнисе дә, әби-бабайлары да нәсел җепләре өзелмәсен, сакланып калсын өчен бик нык тырышканнар, күрәсең. Рәфхәт абый сөйләгәннәрдән шулай сизелә.

Фазлыйулла бабай нәселе

– Безнең фамилия Гафиятулла бабайның әтисе Фазлыйуллага бәйле. Әти сөйләвенчә, аның бабасы Әмирҗан бабай, 1790 елны урыс-төрек сугышында булып, Суворов җитәкчелегендә Измаил крепостен алуда катнашкан. Кыюлыгы өчен көмеш медаль белән бүләкләнгән. Ат җигеп, һәр ай Чабаксар губернасындагы Чуел (Цивильск) өязенә медаль өчен пособиегә йөри торган булган. Фазлыйулла бабамның Әдиятулла исемле туганы була. Аның ике улы – Әхмәдулла белән Зиннәтулланы авылда хәтерләүчеләр күп әле. Алар барысы да вак сәүдә эше белән шөгыльләнгәннәр. Зиннәтулла бабайның кече улы Фәйзрахман абый сөйләвенчә, инкыйлабка кадәр Зиннәтулла бабай патша армиясендә хезмәт иткәндә, Россия белән Германия сугышында камалышта кала һәм әсирлеккә төшә. Аларны Австрия шахтасына җибәрәләр. Бик начар ашаттылар, дип сөйләве истә калган. Әсирләрне аерым хуҗалыкларга эшкә җибәрәләр. Зиннәтулла бабай бер офицер гаиләсенә эләгә. Монда ул үз кешегә әйләнә: бер өстәл янында утырып ашыйлар, бирелгән эшләрне дә төгәл үти. Хәтта бер кызга өйләндереп тә куялар, кызлары туа. Өч ел узып китә. Көннәрдән беркөнне бабайга сугышның тәмамлануын, Россиядә инкыйлаб булуын һәм аның азат икәнлеген әйтәләр. Зиннәтулла бабай туган җиргә кайтып килү теләген белдерә. Ул, авылга кайткач, гаиләсе белән элемтәсен югалта, чөнки элеккеге әсирләр белән НКВД хезмәткәрләре кызыксына башлый. Күп тә үтми, Зиннәтулла бабайны Норлат бае кызы Вәсимә апага өйләндерәләр. Кызның әти-әнисе гаиләсе белән чит илгә чыгып кача.

Зиннәтулла бабайның олы улы Габдулла белән дә кызык хәлләр була. Бөек Ватан сугышы вакытында Псков тирәсендәге сазлыклардагы тар кичүдән штрафникларны чыгарганда, машина белән каршыга маршал Константин Рокоссовский килеп чыга. Ул Габдулла абыйны сазлыкка бәреп төшерә, ә штрафниклар үзләре сикерәләр. Чөнки боерык буенча, кичүдән техника гына чыгарга тиеш була.

Зиннәтулла бабайның туганы Әхмәдулла Себердә сәүдә эшләрендә йөргәндә, аклар кулына эләгә һәм аңа алар армиясендә хезмәт итәргә туры килә. Җаен туры китереп, аклардан кача да авылга кайта. Әхмәдулла бабай озак еллар Айдар авылының умарталыгында эшләде. «Норлат районының иң яхшы умартачысы» дигән белешмәсе дә бар иде.

Гафиятулла бабамның өч улы булган. Әтием Тәлгатулла, энеләре Әсәдулла белән Фәүгатулла. 18 яше тулгач, 1942 елның март аенда әтине Ерак Көнчыгышка армия сафларына алалар. Июнь ахырында ул хезмәт иткән частьны, җиде эшелонга төяп, Сталинград фронтына алып киләләр, 611 нче укчы полкка кушалар. Әтиләргә бер биеклекне алырга әмер бирелә. Кинәт минометлар ата башлый, ә һавада немец самолетлары пәйда була. Солдатларның саны күзгә күренеп кими. Шуышып барганда, әтинең уң кулына пуля эләгә. Кан күп китүдән ул аңын югалта. Новосибирскидагы госпитальдә дәваланып, 1943 елның февраль аенда авылга кайта. Башта колхоз умарталыгында эшли, аннан тавык фермасы мөдире итеп куялар.

Сабир бабай нәселе

Әнием Рәмзиянең тамырлары да бик тирән. Яшь гаилә ата йортында яши. Рәмзия, Мөзәкирә, Нурҗиһан, Фәүзия исемле кызлар янына Габдрахман исемле бер ул туа. Бу гаиләдә зур шатлык була, чөнки ул вакытта ир балага җир биргәннәр. Бабайлар бик тырышып эшлиләр, ныклап аякка басалар. Яңа икътисад сәясәте программасы кабул ителгәч, яңа йорт җиткезәләр, кечкенә генә кибет ачып җибәрәләр. Эш атлары санын арттыралар. Чабыш атлары тәрбиялиләр. Бераздан җил тегермәне төзиләр. Ул авыл халкына 1960 нчы елларга кадәр хезмәт итте әле. Үзән артында бабайларның мунчала күле дә була.

Сабир белән Галимҗан бабаларым үз көчләре белән хәләл мал тапкан урта хәлле крестьян була. Әмма 1930 елны, колхозлар оештырганда, бабайларны кулак дип таныйлар. Ак йортны, амбарларны, конюшняны, тегермәнне колхоз милке итәләр. Ә йорт җиһазларын халыкка өләшәләр. Аларны башта Казан төрмәсендә тоталар, шуннан соң Новосибирск өлкәсенә, бер авылга мәҗбүри эшкә җибәрәләр. Сабир бабай сөргеннән кайткач, озак яши алмый, бакыйлыкка күчә. Ә Галимҗан бабай сугыш елларында Екатеринбург шәһәрендәге химия заводында эшләгәндә каты авырып үлә.

Нигез

Әтием без туып-үскән йортны элекке хуҗасы Таҗиев Шиһап абыйдан сатып алган. Бу нигездә без сигез бала үстек: Рәфхәт, Фәрхәт, Рөстәм, Ризәлә, Сөләйман, Фирдәвес, Нәзилә һәм Гөлинә. Шөкер, барыбыз да гаиләле, балалар үстердек. Хәзер инде оныклар белән мәш киләбез. Төп нигездә яшәүче энебез Фирдәвес, әти-әни эшен дәвам итеп, умарта асрый. Кулы да эшкә ятып тора. Улы Фәнис белән кайчандыр әтием эшләгән тавык фермасы янындагы Әркә чишмәсен карап, буралап куйдылар. Бергә җыелганда, бабайлар калдырган эзләр турында еш сөйләшәбез. Әнинең кечкенә сеңлесе Фәүзия апа да, йорт сатып алып, авылга кайтып урнашкан иде. Фаҗигагә тарып, бакыйлыкка китеп барды. Исән чагында кызы Флюра белән Үзән кизләвен (бабайның тегермәне булгач, аны Сабир кизләве дип тә йөрткәннәр) чишмәне чистарттырып, бик матур өскорма да куйдырганнар иде. Юныс мулладан дога да укыттылар. Эшлисе эшләр күп әле. Бабаларыбызның көчле рухлы, нык булганнарына сөенеп яшибез. Мондый халәт безгә яшәргә дә, эшләргә дә көч бирә.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ



ЛУППОВ АНАТОЛИЙ БОРИСОВИЧ

(02.06.1929 – 08.08.2022)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. Композитор, Татарстан Республикасының халык артисты, Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты Луппов Анатолий Борисович арабыздан мәңгегә китте.

Анатолий Луппов 1929 елның 2 июнендә Киров өлкәсе Тужинск районы Пачи авылында дөньяга килә. 1951 елда Иван Палантай исемендәге Йошкар-Ола музыка училищесын, 1956 елда – фортепиано буенча В.Апресов классында, 1959 елда – композиция буенча А.Леман классында Нәҗип Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясен тәмамлый. Яшь композиторның студент елларында язылган тәүге әсәрләре үк тамашачыларны әсир итә.

Анатолий Борисович, 1954 елдан башлап, 64 елдан артыграк вакыт дәвамында Нәҗип Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясендә укытты, 22 ел буе композиция кафедрасы мөдире, музыка һәм композиция теориясе кафедрасы профессоры булды.

Анатолий Луппов күп кенә музыка жанрларында эшләде. Аның иҗатында музыкаль сәхнә жанрлары: опера һәм балет зур урын алып торды. Ул Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте буенча татар музыкасы өчен тәүге моноопера авторына әйләнде. Рөстәм Кутуйның герой-шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган «Последняя ночь» һәм «Сны военные» шигырьләре буенча иҗат ителгән ике вокаль-симфоник поэмасы премьералары Татарстанның музыка сәнгате өчен зур вакыйгага әйләнде.

Анатолий Борисович Казан дәүләт консерваториясендә эшләү дәверендә бик күп шәкертләрне тәрбияләп, олы юлга чыгарды. Хәзерге вакытта аларның күбесе Россиянең әйдәп баручы композиторлары, күренекле мәдәният эшлеклеләре, иҗат берлекләре җитәкчеләре булып тора.

Анатолий Лупповның югары дәрәҗәдәге һөнәри осталыгы күпсанлы бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – «РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе», «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе», «Мари АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе», «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале, «Фидакарь хезмәт өчен» һәм «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә медальләре, Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты.

Анатолий Луппов һәрвакыт югары дәрәҗәдәге профессионализмы, гаять зур җаваплылык хисенә ия булуы, үз эшенә чиксез тугрылыгы һәм иҗади активлыгы белән аерылып торды.

Талантлы композитор, пианист, педагогның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н. Миңнеханов, М.Ш. Шәймиев, Ф.Х. Мөхәммәтшин, А.В. Песошин, Ә.Ә. Сәфәров, И.Х. Әюпова, И.Р. Метшин, Р.Ф. Кәлимуллин, В.Р. Дулат-Алиев

Яшәеш

БЕРНЕ БИШ ИТИМ, ДИСӘҢ...

АВЫЛ КЕШЕСЕ ҮЗАРА САЛЫМ АКЧАСЫНЫҢ АВЫЛ ӨЧЕН КИРӘК БУЛУЫНА ЫШАНДЫ ИНДЕ

Равил Галимуллин (сулда), Нияз Галимуллин һәм башка егетләр авыл киләчәге өчен көчләрен кызганмый.

Балтач

Балтач районының Бөрбаш авылында үзара салым акчасын ел саен районда иң беренчеләрдән булып җыйнап бетерәләр. Кайбер урыннарда ике йөзәр сум җыйган чакта ук алар бишәр йөз сум җыйды. Быел исә 900 сумнан җыйганнар. Бу – райондагы иң зур суммаларның берсе.

– Бу сан үзара киңәшләшкәннән соң билгеләнсә дә, күңелдә беркадәр шикләнү булды үзе, – ди авыл җирлеге башлыгы Равил Галимуллин. – Әмма күпчелек аңлап, берсүзсез риза булды. Авылда яшәүче төп халык яз башына ук инде биреп бетерде. Соңгы елларда эшләгән эшләр кешеләрнең күз алдында бит.

Бөрбаштагы үзгәрешләр чын мәгънәсендә күңел сөенерлек. Бер яктан Җәлил хәзрәтләре тырыша (кая барса да, сүзе үтә), дәүләт программаларыннан шул сәбәпле мул гына өлеш чыга үзләренә: яңа мәктәп, пансионат, асфальт юллар, мәдәният йортына капиталь ремонт һ.б. Авылдан чыккан эшмәкәрләр белән аңлашып эшләгәнгә һәм үзара салым акчасын авыл кешесе кирәкле дип санаган урыннарга кулланганга, авыл җирлегенә дә ышаныч арта. Иң кадерлесе – авыл язмышына битараф булмаган, «Әйдә, аны эшлик, әйдә, моны эшлик», – дип идея бирүче, үз артларыннан авыл кешеләрен ияртә алучы активистлар да бар биредә. Равилгә менә шушы бөтен мөмкинлекләрдән файдаланырга, кешеләрдәге ышанычны, активлыкны сүндермәскә генә кирәк. Шөкер, үзе дә аңлый һәм шулай эшләргә тырыша.

– Авыл халкы бик активлашты, – дип сөенә ул. – Нинди генә эшкә чакырсак та, каршы килмиләр. Быел кыш авылыбызда яктыртулы чаңгы юлы ачылды. Җәлил хәзрәт фатихасы белән башланган бу изге эш шушы дәрәҗәдә колачлы булыр дип үзебез дә уйламаган идек. Ул урынны куе чытырманлык басып бетергән, бик күңелсез иде. Уйлаштык та, аны чистартып, чаңгы юлы эшләргә булдык. Ул чакта әле яктыртулы трасса турында хыялланмадык та. Сигез көн өмә ясадык, аларда көн саен 40–50 кеше катнашты. Агачларны кистек, әрәмәлекне чистарттык. Язын исә агачларның төпләрен чыгарырга куәтле техникалар, зур суммада акча кирәк иде. 500 мең сумлык ярдәмне авылыбыздан чыккан эшмәкәр егетләр Нияз Галимуллин, Илдар Галиуллин, Бөрбаш Сәрдегәненнән Габделнур Хөсәенов күрсәтте. Аннан соң ул урын чаңгы шуарлык хәлгә китерелде. «Башта гади чаңгы юлы ясыйк әле, авыл халкы шуамы-юкмы, шөгыльләнүчеләр күп булса, аннан яктыртуны да хәл итәрбез», – диде Нияз Галимуллин. Һәм сүзендә торды. Яктыртуны да үз өстенә алды, кар чанасы, аның артына тагу өчен кыйммәтле ике җайланма алып бирде. Ниязның авылыбызга булган игелекле гамәлләре бик күп. Бездә туып-үсмәсә дә, әтисе Рафил абый яшьли вафат булса да, авыл белән элемтәсен өзмәде. Аны шундый итеп үстергән, әти ягы туганнарын, аның туган авылын хөрмәтләргә өйрәткән әнисе Алия апага бик рәхмәтле без. Гомумән, бу яктыртулы чаңгы юлына гына да иганәчеләребез бөтенесе 1 миллион 500 мең сумлык ярдәм күрсәтте. 200 метр юлга таш та түшәлде, чишмәсе дә тәртипкә китерелде. Җәлил хәзрәт тырышлыгы белән ачылу тантанасы исә авыл бәйрәменә әйләнде.

Аңа кадәр дә инде өмәләр үткәреп, авылдагы шактый урыннарны тәртипкә китергән бөрбашлылар, яктыртулы чаңгы юлы турындагы хыяллары чынга ашуга, бу кышта ук яңа планнар кора башлый. Хыялланып кына калмыйлар, әлеге күпернең икенче ягындагы чүплекне дә чистартып, нәкъ теге ягындагы кебек үк агачларын кисеп, тәртипләп куялар. Биредә яр буе паркы төзергә җыеналар. Бу юлы инде үзара салым акчасына.

– Язга чыккач, ул урынга планировка ясаттык, – дип сөйли Равил. – Бу үзебезнең көчтән генә килә торган эшләр түгел, зур чыгымнар сорый. Куәтле техникалар кирәк. Илһам Мөҗипов ширкәте егетләре тиз дә, сыйфатлы да эшләделәр. Быелга тагын 218 метр җәяүле сукмагы эшләтү планга кертелгән, яктыртуларын киләсе елгы үзара салым акчасына эшләтәчәкбез. Быел җыйналган акчаның калган өлеше моңа кадәр эшләнгән урыннарны тәртипкә китерүгә тотыла. Үткән ел без шундый 50 мең квадрат метр мәйданның үлән-чүпләрен чаптыртканбыз. Быел да шушы кадәр мәйданны җәй буена ике-өч тапкыр чистартабыз...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

РӨСТӘМ МӨХӘММӘТДИНОВ:

«Төшкә дә басу керә»

Республика кырларында уракның иң кызган чагы: игенчеләр ашлык җыя. Ашлыкны югалтуларсыз җыеп алу өчен, бар көчен биреп эшли алар. Зәй районының Бура-Киртә авылы егете Рөстәм Мөхәммәтдинов – әнә шундый яшь комбайнчыларның берсе.

Рөстәм Мөхәммәтдинов – комбайнчы-механизаторлар нәселеннән. Бабасы Мөнәвир Мөхәммәтдинов гомере буе комбайнчы булып эшләгән, әтисе Марат – бүген дә алдынгы игенче. Кечкенәдән әтисе һәм бабасы белән техника янында кайнашып үскән егетнең механизатор һөнәрен сайлавы һич гаҗәп түгел.

– Мин 6 нчы сыйныфтан соң ук, әти белән бабайга ияреп, кыр эшләрендә катнаштым. Соңыннан инде үзем аерым комбайнга, тракторга утырып эшли башладым. Барысын да алар өйрәтте. Бабай әле дә сафта, безгә техника ремонтлауда булыша, киңәшләрен бирә, – ди Рөстәм.

Мәктәпне тәмамлагач, Рөстәм Зәй политехник көллиятендә тракторчы-машинист белгечлеге ала. Биредә укыганда Казанда төбәкара «Яшь профессионаллар», Лаеш районында авыл хуҗалыгы техникасын эксплуатацияләү буенча бәйгеләрдә катнаша. Сарманда һөнәри осталык чемпионаты җиңүчесе була. Узган ел яшь комбайнчылар арасында уздырыла торган «Хезмәт кешесен данлыйбыз!» республика бәйгесендә призлы урын яулый.

Авыл һавасын сулап, җир сулышын тоеп үскән егет хәрби хезмәттә дә сынатмый. Армиядән кайткач, икенче көнне үк әтисе белән комбайнны уракка әзерләргә чыга.

– Үзенә күрә бер чир инде ул. Урып-җыю сезонын түземсезлек белән көтеп алам. Басу-кырларсыз яши алмыйм, аларны иңләүдән дә рәхәт нәрсә юк. Төшкә дә басу керә, – ди егет.

Урып-җыю чорында Зәй районының иң нәтиҗәле эшләүче комбайнчыларның берсе дә ул. «Зәй» агрофирмасында хезмәт куя. Быел тугызынчы сезонын эшли.

– Алты ел әти белән бабайның ярдәмчесе булып эшләдем. Өченче ел инде комбайнны үзем иярлим. Яхшы күрсәткечләргә ирешкән елларда Президентыбыз Рөстәм Миңнехановның 100 мең сумлык премиясен, район башлыгыбызның премияләрен алдым. Хәзер кырларда арпа суктырабыз. Быел уңыш әйбәт. Иң мөһиме – игенне вакытында югалтуларсыз җыеп алу. Ә моның өчен барлык шартлар да бар, – ди яшь комбайнчы.

Ләйсән САФИНА

Бәллүр каләм – 2022

«Бәллүр каләм» журналистика һәм массакүләм медиа өлкәсендәге республика бәйгесенә быел 1700дән артык эш килгән. Икенче турга үткән 51 катнашучыдан 18е финалга чыккан.

ҖИҢҮЧЕЛӘР

«ЕЛ МЕДИА-ШӘХЕСЕ»

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе
Фәрит МӨХӘММӘТШИН

ГРАН-ПРИ

КФУның Милли һәм глобаль медиа чаралары кафедрасы мөдире
Васил ГАРИФУЛЛИН

«ЖУРНАЛИСТИКАГА ТУГРЫЛЫК»

Әскәр САБИРОВ
(«Татарстан» журналы)

Инсаф АБДУЛЛИН
(«Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе)

«ҺӨНӘРДӘ ИҢ ЯХШЫСЫ»

Михаил ЛЮБИМОВ
(«Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе)

Гөлназ ШӘЙХИЕВА
(«Татарлар» газетасы)

Гөлнар ГАРИФУЛЛИНА
(«Интертат» электрон газетасы)

«ЕЛ ФОТОРЕПОРТЕРЫ»

Анна АРАХАМИЯ
(«Сөембикә» журналы)

«ЕЛ ТЕЛЕОПЕРАТОРЫ»

Андрей КОРСИНСКИЙ
(«Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе)

«МУЛЬТИМЕДИАЛЫ РЕДАКЦИЯ»
«Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясенең мәгълүмати программалар хезмәте
«Ялкын» журналы

«ИҢ ЯХШЫ РАЙОН (ШӘҺӘР) РЕДАКЦИЯСЕ»
«Казан утлары» журналы
Балтач районының **«Хезмәт»** газетасы

«НӘТИҖӘЛЕ МАТБУГАТ ХЕЗМӘТЕ»
ТНГ-групп матбугат хезмәте (Бөгелмә)

«ПОПУЛЯР БЛОГЕР»
«ШАЯН ТВ»

«ТУГАН ТЕЛ»
«Яңарыш» нәшрият үзәге (Ижау)

МАХСУС НОМИНАЦИЯЛӘР

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫН ИҢ ЯХШЫ ЯКТЫРТУ»
«Ватаным Татарстан» газетасы
«Актаныш-информ» мәгълүмат үзәге
Өстәмә бүләк: **«Мин этине өйрәтәм»** проекты өчен
«Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе

«РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНДӘ ФӘН ҺӘМ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ЕЛЫН ИҢ ЯХШЫ ЯКТЫРТУ»
«Геофизик Татарии» газетасы (Бөгелмә)
«Татарстан–24» телеканалы

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ИЛКҮЛӘМ ПРОЕКТЛАРНЫ ЯКТЫРТУ БУЕНЧА ИҢ ЯХШЫ РЕДАКЦИЯ»
«Нократ» газетасы редакциясе (Мамадыш районы)
«Сарман» газетасы

ДИН ҺӘМ МИЛЛӘТ: ЮЛ УРТАК, СУКМАК БЕРМЕ?

Сорау – җавап

Милләт – динне, дин милләтне саклаган, дияргә яратабыз. Ә ни рәвешле? Хәзер милләт белән дин төшенчәләрен бер яссылыкта карарга мөмкинме? Аларны ни берләштерә? «ВТ» хәбәрчесе «Печән базары»нда «Тәртип» радиосы тарафыннан оештырылган «Ислам һәм милләт» дигән лекцияне тыңлап кайтты. Очрашуның кызыклы өлешләрен сезгә дә тәкъдим итәбез.

Сорауларга «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы Нурулла хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН җавап бирде.

«Татар» безгә ник кирәк?

«Татар» дигән халык юк. «Гарәп» дигән халык та юк. Элек чүлдә яшәгән һәр кешене «гарәп» дип атаганнар. Төрки телдә сөйләшкән һәркемгә «татар» дигәннәр. Барыбыз да татар булсак та, без үзара аерылабыз. Кара тәнле татар да бар, сары чәчле дә. Кысык күзлесе, зур күзлесе дә. Әмма барысы да татар дип йөртелә. «Татар» дигән исем совет чорында популярлашкан. Бу чорга кадәр бу халыкны «мөселман» дип йөрткәннәр. «Син нинди милләттән?» – дип сорамаганнар бит. «Син кем өммәтеннән?» – дип сорау биргәннәр. Бу – феномен, тарихта мондый бер генә очрак билгеле. Татар халкы өчен беренче урында дин торган.

Болгар ханлыгы ислам динен кабул итте, дибез. Меңләгән халык дин тирәсенә берләшкән бит, ә милләт тирәсенә түгел. Димәк, дин дә, милләт тә бер-берсен тулыландырган, тик бер-берсенә бәйләнмәгән.

«Татар» дигән атама кирәкме соң безгә? Бик кирәк! Хәзер инде Россиядә яшәгән халыкны без дин белән бәйли алмыйбыз. Ник дисәк, ул диннән бик ерагайды. Татар кешесен урамда күрсәк, без карап кына аның татар кешесе икәнен әйтә алмыйбыз. «Татар» дигән төшенчә безне берләштерер өчен кирәк. Кызганыч, хәзер тышкы көчләр татар халкын, башка төрле атамалар кушып, бүлгәләргә тели.

Өстенлек кайсына: динме, милләтме?

Безнең арада татар халкы өчен янып-көеп йөргән милләтчеләр күп. Әмма аларның күбесе үзләрен дингә бәйләми. Дин белән милләт дигәндә, кайсын беренче урынга куярга? Акыллы кеше: «Икесен дә», – дияр. Кайсылары: «Без билгеле бер милләттә туган, шуңа милләт беренче, динне сайлыйбыз», – дияр. Дөрестән дә, татарлар арасында да атеистлар һәм христианнар бар.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дигән: «Без сезне халыклар, милләтләр, кабиләләр итеп яраттык». Тагын бер аятьтә: «Аллаһы Тәгаләнең әмере бу – сезнең тел һәм тәнегезнең төсе төрле булу», – диелә. Милләт дингә каршы килә торган нәрсә түгел. Дөрес, кара тәнле кешене күрсәк, без аңа «татар» дип әйтә алмыйбыз инде. Кысык күзле Кытай кешесенә дә «татар» димәбез.

Әмма «милләт» дигән төшенчә нәселдән-нәселгә күчәме икән? Тәнебезнең төсе генә күчә. Тел күчми, гореф-гадәт, кием, милләт күчми. Әйтик, Африкадан бер баланы алып кайтып, аны татар авылында тәрбияләсәң, ул татарча сөйләшәчәк. Крокодил кирәк, димәс, сарык ите ашар. Миңа пальмалар кирәк, дип йөрмәс, талларга үрелер. Адәм галәйһиссәлам дә билгеле бер милләттән булмаган.

Һәрбер халыкның яхшы һәм начар ягы бар. Пәйгамбәребез (с.г.в.) бер аятендә: «Начар якларыңны башкаларга карап төзәт», – дигән. Милләтләр арасында көнчелек хисе туарга тиеш түгел. Бу милләттә болай, тегесендә тегеләй, дияргә ярамый. Һәр халык үзен күтәрергә тырышса да, бүтәннәрне кимсетергә хакы юк аның.

tatarstan.ru

Киләчәк турында

Татар халкын саклап калып буламы? Болай барса, юк. Гаяз Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрен искә алыйк. Инкыйлабка кадәр язылган әсәр бу. Татар халкына 200 ел вакыт бирелә. Азагын хәтерлисездер. Иң ахырда мулла үлә һәм аның өстенә мәчет манарасы төшә. Бу – соңгы татар була. Әсәр язылганнан соң шактый вакыт үтте инде. Исхакыйның сүзләре чынга аша бара. Елдан-ел татар телендә сөйләшә белүче халык кими. Бер ел эчендә берничә йөз меңгә! Гореф-гадәтләрен белүчеләр аз, динен белүчеләр исә 5 процент кына! Татар телендә сөйләшә һәм бу телне аңлый белгән буын – безнең буын. Безнең балаларыбыз татарча аңлый, ләкин сөйләшми, оныкларыбыз аңламый да, сөйләшми дә. Бу – куркыту да түгел, ачы хакыйкать. Болай дәвам итсә, матур киемнәр кидереп, татарча сөйләштереп, «карагыз, татарлар шундый булган» дип, маймыл чыгарып күрсәтүгә генә калмаска иде.

Вазгыятьне ничек үзгәртергә соң? Татар халкы үз асылыннан кайчан китә башлады? Совет чорында. Ни өчен? Бу вакытта дин юкка чыкты. Халыкны дин генә тотып торган. Совет чорында кеше теләсә нинди ризык ашый, теләсә нинди кием кия башлады. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Кем башка халыкка охшаса, ул шул булыр», – дигән. Дин киткәч, без Европага борылдык. Балаларыбызга да чит исемнәр куша башладык. Бу – мөселман исемнәре түгел.

Татар халкын рус теленә күчерделәр, татар телендә сөйләшү дә оят иде. Дин беткәч, милләт тә бетә башлады.

Милләтнең һәм диннең үзара бәйләнеше бик тыгыз. Аны аерым карап булмый. Кем аерып карый икән, димәк, ул татар халкын белми.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ҮЗ КОЯШЫМ...

Бу хакта бик күп тапкыр әйткәнем дә, язганым да бар бугай инде. Мин күкне күзәтергә яратам. Ишегалдының яшел чирәменә сузылып чалкан ятасың да күккә карыйсың. Кояш инде анда, кояш нурының ак болытларда чагылышыннан күзләр әлҗе-мөлҗе килеп тора, соңыннан бераз күнегә төшәләр һәм дөньяның бөтен нуры җаныңа сеңә, үзең дә бер нурга әйләнгән кебек буласың. Рәхәт инде шундый. Ә бу юлы мин ишегалдында йокларга булдым. Ачык һавада. Быел бездә черкиләрдән бик юк, җил бар, салкынлык бар… Тик ышык урында киенебрәк ятсаң, боларның зыяны сизелми. Мин дә ихатадагы тотынылмый калган яңа такталардан карават кебек нәрсә корыштырып куйдым да, аска иске толып җәеп, җәй буена өстән төшмәгән бишмәтне киеп, сузылып яттым.

Төнге күк йөзенең үз матурлыгы бар аның. Юк, әле йолдызлары да чыкмаган иде. Ниндидер сыек томан булып, болытка әверелә алмый каңгырып, караңгылык кына йөзеп йөри. Ак болытлары да юк. Ә төнге күктә ак болытлар да якты булып тоела. Бүген алар да юк. Тик барыбер күк йөзе бар. Болытсыз һәм йолдызсыз һаваның да үз матурлыгы, үз серлелеге бар. Син мәңгелек белән очрашкандай буласың. Үзеңне галәм уртасында яткан кебек хис итәсең. Мәңгелек уртасында…

Менә шушы мәңгелек уртасында мин йоклап киткәнмен. Уянсам, баш очымда гына – кара болыт. Куе инде шундый… Малевичның «Кара квадрат»ы бар бит әле… Менә шул Малевич галәм биеклеге булып үскәндер дә үзенең квадратына сибәргә дип әзерләп куелган зур чиләктәге дегетен чайпалдырып җибәргәндер сыман. Чиләктән чайпалган дегет, җиргә төшеп җитә алмыйча, минем өстә асылынып калгандыр…

Беренче карашка гына шулай тоелды ул, ә икенче мизгелдә бөтенләй куркыныч булып китте. Чынлап куркырга теләсәң, галәм белән йөзгә-йөз калырга кирәк. Галәм ул – мәңгелек, ә мәңгелектән дә коточкычрак берни дә юк. Кешенең авыр һәм кара уй-фикерләре, кылган һәм кылып өлгермәгән гөнаһлары беркая да китми, ә Җир шарын әйләндереп алган бер катламда саклана дип әйтәләр бит әле… Эзотерика дигән нәрсә шөгыльләнә шундый фаразлар белән. Мин аңа тулысынча ышанып бетмим инде, тик кире дә кага алмыйм. Барлык белемнәрне бер яссылыкка куеп карасаң, ул бик ышанычсыз нәрсә дә булып тоелмый. Менә шушы фаразын гына алсак та… Безнең кара уйлар, гамәлгә ашмыйча калган гөнаһлар, матдиләшеп, күккә күтәрелә. Галәмнәрдән килгән яктылыкны җанга индермичә, кара болыт булып, бар тормышны каплап тора. Төрле диннәрне һәм тәгълиматларны бер яссылыкка куеп тикшергән бер язмамда мин моны бик тәфсилләп аңлатырга маташкан идем инде, шуңа нечкәлекләренә бирелеп тормыйм. Кыскасы, менә мондыйрак күренеш. Төн уртасында уянып китсәм, өстемдә – кара болыт. Һәм ул болыт фән аңлатканча, яңгыр тамчыларыннан түгел, ә минем көнелдәге кара тойгылардан, моң-зарлардан, канәгатьсезлекләрдән, сүгенүләрдән, кылган һәм кылып өлгерә алмаган гөнаһлардан хасил булгандыр сыман тоелды.

pinterest.com

Куркыныч булып китте…

Һәм мин, җанымның бөтен яктылыгы белән шул болытны таратырга теләп, күккә текәлдем. Нурларымны бер ноктага төбәргә теләп, күзләремне ачып-йомып алдым. Болыт таралыр, һич югы телгәләнер шикелле тоелды. Тик ул һаман үз көенчә калды. Берни дә үзгәрмәде. Шулай тиештер инде ул, бәлки, гомерең буена җыелган караңгылыкны таратырга мизгеллек балкулар гына җитмидер.

Һәм мин өйгә кереп яттым. «Йортым – минем кальгам», – дип әйтәләр бит. Йортың саклый инде сине. Дошманнардан гына түгел, һәртөрле шикле уйлардан, хорафатлардан да. Түшәмнең ак тактасына карап, озак кына яттым әле. Түшәм-түбә өстендә дә теге болыт асылынып торадыр сыман тоелды. Һәр кешенең үз болыты бардыр инде һәм ул һәрчак аның белән бергә йөридер.

…Иртән җиргә кояш чыккан иде. Ул миңа үз кояшым булып тоелды. Үземнең күңел нурларыннан, җаным балкышыннан хасил булган кояш. Бәлки, чынлап та шулайдыр. Һәр кешенең үз кояшы бардыр. Ә болытлары бары тик кояш ял иткәндә генә күренәдер.

Баш очымда үз кояшым булсын, дип теләдем мин.

Хәтта төннәрен дә…

Марат КӘБИРОВ

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6688 данә
Гомуми тираж – 15838 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 315

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+